# Бөек Җиңүгә 80 ел

**Алып баручы.** Хәерле көн, хөрмәтле авылдашларыбыз, хезмәт ветераннары, килгән кунаклар! Сезнең барыгызны да олы тантана - Бөек Җиңүнең 80 еллыгы белән котлыйбыз. Сугышның барлык авырлыкларын үз җилкәләрендә татыган, олы тормыш юлы үткән сугыш чоры балалары, хөрмәтле кешеләребез бүген биредә, безнең арада. Бүген без, сезгә дан һәм мәдхия җырларга, сезнең түземлегегез һәм сабырлыгыгыз алдында баш ияргә җыелдык.

Хөрмәтле, тыл ветераннары, сугыш чоры балалары! Бүгенге бәйрәм өчен оештырылган чарабызны сезгә багышлыйбыз.

<u>Гимн РФ и РТ (фонограмма)</u>

**Алып баручы.** Сугыш...Нинди авыр, каһәрле, шомлы сүз бу! Ул ничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган...

Сугыш...Меңәрләгән шәһәрләр җимерелгән, җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән.

Егерме ике. Июнь.
Кырык бердә
Җиргә афәт килде ул көнне.
Тарих каһәрләгән шушы көнне
Мөмкинме соң оныту, мөмкинме?

1941нче елның 22 нче июнь иртәсе. Явыз һәм көчле Гитлер Германиясе сугыш игълан итмичә илебез чикләрен бозып керде. Тыныч шәһәрләр һәм авыллар өстенә меңләгән бомбаларын яудырды. Сугыш башланды!

Илебез халкы 1418 көнгә сузылган дәһшәтле Бөек Ватан сугышына күтәрелде.

**<u>Җыр “Солдатлар”</u>**

Озатып, вокзаллар каршында
Маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар.
Балалар керделәр утларга,
Балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
Калдылар еракта йокларга…
«Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында!..»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында…
Уятма, йокласын, син ана,
Айларны, елларны санап бар.
Йөрәктә һаман яшь, гел бала–

Кайтмаган солдатлар, солдатлар…
Ана ул йокламый, сабые
Юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле,
Мәйданда Мәңгелек ут яна.
Аналар йөрәге шикелле
Ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында…

**Азамат**
Яшь каеннар яфрак ярган чакта,
Яшь каендай зифа егетләр,
Ил бурычын иңнәренә салып,
Утка төренеп, яуга керделәр.
Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк елый Муса, Алиш өчен,
Егермеләп миллион җан өчен!
Яңгыра, җыр, газиз илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып,
Батырлыгы булып халкымның!

**Наил**
Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә — балам. Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм.
Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...
Бәлки, соңгы тапкыр — күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.
Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!» — ди ул күңеленнән,
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.
Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм.

**Чулпан**
Кирәкми безгә кан кою,
Кирәкми безгә сугыш!
Безнең теләк якты, матур,
Тыныч хезмәт һәм тормыш.
Илебез зур, җиребез киң,
Хисапсыз байлык бездә!
Җир өстендә, җир астында,
Тауларда һәм диңгездә.
Без үз кулларыбыз белән
Төзибез гүзәл тормыш.
Без – тыныч ил төзүчеләр,
Кирәкми безгә сугыш

**Данияр**
Кайтыр иде егет, юлы урау,
Каршысында текә таулар бар.
Киртә түгел таулар, тау артында
Коралланган көчле яулар бар,
Ташка басып егет кылыч кайрый,
Акбүз аты йөри аланда.
Ялын болгап кайчак кешнәп куя,
Нидер әйткән төсле аңарга.
— Тиз бул, егет, тиздән кояш баер,
Зәңгәр томан каплар болынны;
Адашырбыз, юлны югалтырбыз,
Табалмабыз таныш урынны...
— Курыкма, атым, кыю “чикмәнле”нең
Караңгы төн туры юлдашы.
Безне көтә сугыш, тик артыннан
Без килгәнне дошман тоймасын.
Җиңү безгә туры юл күрсәтер,
Томан тетелер ал таң нурыннан.
Туган йортны, дускай, без табарбыз
Сөйгәнемнең сагыну җырыннан.

**<u>Җыр “Җиңеп кайт!”</u>**
Чулпан калка, таң ата,
Кыз сөйгәнен озата,
Исән барып, исән кайт,
Дошманнарны җиңеп кайт!
Миннән сиңа теләк шул —
Ил мактарлык үрнәк бул.
Мин тагын телим сиңа —
Үткенлек кылычыңа.
Быргы уйный еракта,
Туплар сөйләшкән якта.

Егет китте шул якка,
Атланып аргамакка.
Теләр идем тагын да,
Бик сагынган чагында, —
Язып җибәр сәлам-хат!
Сау бул, җиңеп кайт!

**Таһир**
Сугыш бара яу кырында,
"Әткәй, ничек хәлләрең?"
Күптән юк бит, белалмыйбыз,
Нигә юк бер хәбәрең?
Киткән чакта күрми калдым,
Мәктәптә идем, әткәм ...
Борылып, борылып карагансың -
Күренмәсме дип бәбкәң.
Бер хәбәрең булды бары,
"Җиңеп, алга барабыз..."
Өзгәләнеп, хәбәр көтеп,
Сине сагынып калабыз.
Килде хәбәр командирдан,
"Госпитальдә улыгыз...
Нык яралы, хәле авыр,
Зинһар, сабыр булыгыз"
Сине көтеп газиз әткәй,
Тәрәзәдә гел күзем...
Җиңү яулап кайт, тизрәк -
Нык бул, әткәй, бирешмә син -
Була күр һәрчак түзем.

**Мәрьям**
Бер кайтырбыз диеп киткән юлдан
Китсәләр дә алар кайтмады.
Алар өчен бары жилләр генә
Ачып-ябып йөрде капканы.
Алар өчен янды ялгыз гына,
Күз нурларын сирпеп еракка.
Тик ил өчен, геройларча, дигән
Хәбәр генә кайтты бу якка.
Хәбәр генә кайтты буякларга
Ядкарь булып газиз анага…
Һәм ир даны кайтты югалмыйча,
Мәңгелек ут булып янарга.

**Ранис**
Балалар уйныйлар «сугышлы» уены,
Сугыш ул — аларга тик уен.
Ә минем уемда кайтмыйча калганнар —
Егерме миллион, егерме миллион.
Тол килеш картайды, агарды чәчләре,
Ишләрен тапмады күп куен.
Куенга алыр да терелтер идем мин…
Егерме миллион, егерме миллион.
Яз килгәч шыталар кан төсле чәчәкләр,
Котлыйлар Җиңүне — ил туен.
Мәйданда ут яна, мәйданда — чәчәкләр…
Егерме миллион, егерме миллион.
Карыйм да кояшка, эндәшәм дөньяга:
Тынычмы күңелең, ни гамең, ни уең?
Мин түгел, мин түгел, эндәшә дөньяга
Егерме миллион, егерме миллион!

**Вильдан**
Сугыш бетеп, илгә җиңү килде,
Күп әтиләр кире кайтмады.
Сандык төпләрендә саргайдылар
Окоплардан язган хатлары.
Кайтыр дигән өмет белән калды
Якыннары, туган яклары.
Ә безгә тик истәлеккә калды
Өчпочмаклы әти хатлары.
Газиз әнкәм, балам укыр, диеп,
Ак әманат итеп саклады.
Әниемнең кайнар яше тамган
Әле дә исән әти хатлары.

**Раиф**
Офыкларга тулды кара төтен,
Төсен алды төтен далаларның.
Елга булып яше җиргә сеңде
Сугыш чорындагы  балаларның.

Ил хәсрәте ирләр иңсәсендә,
Ат чыдамый торган авыр хезмәт.
Алтмыш тулмый җиргә иңә ирләр,
Илгә рәнҗеп, күрми кадер, хөрмәт.

Хәтер, төпкеленнән ачы язмыш
Сөрән сала авыл, калаларга.
Уйчан йөзләр, әле дә моңсу күзләр
Сугыш чорындагы  балаларда.

**Гарник**
Майский праздник –
День Победы
Отмечает вся страна.
Надевают наши деды
Боевые ордена.
Их с утра зовёт дорога
На торжественный парад,
И задумчиво с порога
Вслед им
Бабушки глядят.

**Марианна**
Мой прадед
Рассказал мне о войне.
Как в танке сражались,
Горели в огне,
Теряли друзей,
Защищая страну.
Победа пришла
В сорок пятом году!
Вечернее небо,
Победы салют,
Солдаты России
Наш сон берегут.
Я вырасту –
Детям своим расскажу,
Как прадеды их
Защищали страну.

**Нигина**
Бәйрәм килә,бөек җиңү көне,
Горурлык һәм шатлык күңелдә.
Ветераннар уза колоннада,
Алар әле сафта бүген дә.
Күпләре юк инде безнең батырларның,
Алып китте хәтер дәфтәрен.
Канлы сугыштагы югалтуны,
Әйтә алмый безгә күргәнен.
Күпләр ятып калды яу кырында,
Якынайтып җиңү көннәрен.
Зарыгып көтте өйдәгеләр аны,
Күз яшьләрен түгеп төннәрен.
Көнне-төнгә ялгап эшләделәр,
Бөтен халык ару белмичә.
Фронтка дип икмәк үстерделәр,

Авырлыктан башны имичә
Буе җитәр-җитмәс яшь үсмерләр,
Снарядлар кырды станда.
Дошманнарга ут яудырыр өчен,
Илебездән кире куарга.
Дистә еллар инде узып китте,
Тыныч тормыш безгә килгәнгә.
Мәңгелек дан сезгә ветераннар,
Бөек җиңү бүләк иткәнгә.

**Марат.**
Ил сагында тора ир-егетләр,
Саклап безнең тыныч тормышны.
Чикләр тыныч, илдә муллык өчен,
Үти алар изге бурычны.
Ил сагында тора ир-егетләр,
Бөркет кебек саклап күкләрне.
Һаваларны кочып “тимер кошларында”
Кабат кайтармаска үткәнне.
Ил сагында тора ир- егетләр,
Корабларда йөзеп диңгездә.
Дошман пычратмасын суларны дип,
Уяу тора көнен-төнен дә.
Ил сагында тора ир- егетләр,
Иксез-чиксез дала, тауларда.
Кара көчләр борчымасын өчен,
Илдә гөрләп томыш барганда.

«Бер кайтмасак, бер кайтырбыз», дип китсәләр дә, 111авылдашыбыз яу кырында мәңгелеккә ятып калды, күбесе кайткач вафат булды. Туган җирләре өчен башын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада.

Кабереӊ кайдадыр, билгесез,
Туфрагыӊ күмгәндер үләннәр.
Китмиләр күӊелдән беркайчан
Ил өчен көрәшеп үлгәннәр.

Кайтмаганнар
Уйда сакланалар,
Җырда ятланалар
Кайтмаганнар…

Исемнәре данга төрелгәнгә
Һәйкәл булып басты
Кайтмаганнар!
Баш иябез сезгә, каһарманнар!

Хөрмәтле кунаклар, ветераннар! Якты киләчәгебез, сабыйларның тыныч йокысы өчен гомерен биргән авылдашларыбызны олы ихтирам белән искә алыйк. Бер минутка тынлык.

**<u>Минута молчания (метроном)</u>**

Сугыш кырында ятып калган авылдашларыбызның, якыннарыбызның яткан җирләре йомшак булсын, туфраклары җиңел булсын. Аларның һәркайсын хәер – догалар белән искә алып китик.

**<u>Сүз авылыбыз имамы Марат хәзрәткә бирелә.</u>**
**<u>Сүзне ветеран уытучы Гәүһәрия апа Шиһаповага бирәбез.</u>**
**<u>Сүзне сугыш чоры баласы Әлфинур апа дәвам итә.</u>**

---

---

Туктатырга фашист “тирмәнен”.
Тугрылыклы булып үз антына,
Якынайтып җиңү көннәрен.
Җиңү килде, Бөек җиңү!!!
80-нче язы ургылып.
Мәңгелек дан сезгә ветераннар,
Алсу таңнар атсын сызылып.

2 нче сыйныфлар башкаруында бию, җыр.

1945 нче елның 9 нчы маенда озак көткән Жинү көне килә. Жиңү шатлыгы белән бергә ачы хәсрәт, сагыш та алып килә ул. Толлар, ятимнәр бу сагышны гомерләре буе күнелләрендә йөртәләр.
Хөрмәтле өлкән буын кешеләребез! Сезнен арада сугыш жилләре кагылмаган кеше бармы икән? Берәүләрегез сугыш утында булса, икенчеләрегез тылдагы авыр хезмәтне, ачлыкны башыннан үткәргән, өченчеләрегез әтисезлек хәсрәтен гомер буе кичергән. Сугыштан сонгы авыр хезмәт, ятимлек сезнең күңелләрне катырмаган, рухыгызны сындырмаган.
Без, яшь буын, сезнең тормыш сөючәнлегегезгә, кешелеклелегезгә, эшчәнлегегезгә сокланабыз. Рәхмәт, сезгә!

Үлгәннәр хөрмәтенә веноклар кую.